ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ

«ВТ» хәбәрчесенең ил-көн вакыйгаларына күзәтүе

> 2

ЗИРАТКА... ХЕЗМӘТКӘ!

Питрәчтән Равил Ногманов мәңгелек йортта эшли һәм 120 яшькә кадәр яшәргә хыяллана

> 3

МОҢ ИЯСЕ

Җырчы Гөлшат Имамиеваның тормыш сәхифәләрен барладык

> 4

ЯЛКЫН ТЕЛЕ

Һава температурасы түбәнәйгән чорда уяулыкны арттыру кирәк

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 177 (28950) | Чәршәмбе | 30 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САКЛАР ҺӘМ САКЛАНЫР ЧАК

Сәламәтлек

Узган атнада Татарстанда балага арка миен күчертеп утырту буенча беренче уникаль операция ясала башлаган. Республикада 15 медицина хезмәткәре өлешчә мобилизациягә эләккән. Татарстанда районнарга йөри торган тагын бер күчмә сырхауханә машинасы булачак. Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков катнашында Хөкүмәт йортында узган брифингта яңгыраган иң төп яңалыкларның берничәсе болар.

Илкүләм проектлар

Татарстанда «Сәламәтлек» илкүләм проектын тормышка ашыру өчен 4,2 миллиард сум акча сарыф ителгән. Бу акчаның яртысыннан артыгы (60 процент) беренчел звено тармагын яңартуга тотылган. Аның кысасында быел республикада 34 сәламәтлек саклау объекты төзелгән, 15е төзекләндерелгән, 22 транспорт чарасы сатып алынган.

Гомер озынлыгын арттырып, үлем-китем очракларын киметергә кирәк. Министр якын киләчәккә билгеләнгән иң төп бурычларның берсе дип шуны атый. Быелның ун ае нәтиҗәләреннән аңлашылганча, Татарстанда уртача гомер озынлыгы 73,8 яшь тәшкил итә. Бу күрсәткеч буенча республика Идел буе төбәкләре арасында беренче урынга ук чыккан.

Бер ел эчендә республикада үлем-китем очраклары кимегән. Бүген Татарстанда бер мең кешегә 11,6 үлем очрагы туры килә. Узган ел бу сан 15,5 очракны тәшкил иткән. «Монда коронавирус та зур роль уйнады. Бүген төп максат – Татарстанда үлем-китем очракларын 2019 елгы дәрәҗәгә төшерү. Ул чакта республикада бер мең кешегә 11,0 үлем очрагы туры килә иде. Бу – күпьеллык күзәтүләр тарихындагы иң түбән күрсәткеч», – ди Марат Садыйков.

Мобилизация

Сентябрь азагында Россиядә игълан ителгән өлешчә мобилизация сәламәтлек саклау тармагын да читләп үтмәде. Марат Садыйков сүзләренә караганда, Татарстанда 15 медицина хезмәткәре өлешчә мобилизациягә эләккән. Аларның бер өлеше алдынгы сафларда хезмәт куя, икенчеләре хәрби госпитальләрдә эшли.

– Мобилизация сәламәтлек саклау тармагындагы кадрлар мәсьәләсенә зыян салмады. Табибларга кытлык юк. Татарстан табиблары, җирле халыкка ярдәм итү өчен, Донецк һәм Луганск халык республикаларына да даими рәвештә барып тора, – дип искәртте министр.

Марат Садыйков сүзләренә караганда, табиблар арасында үз теләге белән махсус операциягә китүчеләр дә байтак. Министр аларның төгәл санын атый алмаса да, мобилизациягә эләккән егетләр белән дә, анда үз теләге белән киткән белгечләр белән дә элемтәдә торуларын әйтте.

minzdrav.tatarstan.ru

Чикләүләр

Россиягә каршы кертелгән чикләүләр Татарстанның сәламәтлек саклау тармагына тискәре йогынты ясамаган. Әмма министр киләсе елда бу юнәлештә кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин дип фаразлый.

– Февраль аендагы вакыйгалардан соң кыенлыклар килеп чыгар дип уйлаган идек. Үзегез дә хәтерлисездер, ул чорда даруханәләрдә кайбер препаратларга кытлык та булды. Әмма бу кытлык дарулар кайтарту белән кыенлыклар булганга түгел, халыкның кирәксә-кирәкмәсә дару җыюы аркасында килеп чыкты. Импортлы җиһазлар белән дә кыенлыклар юк иде. Тик киләсе елда бу юнәлештә проблемалар килеп чыгарга мөмкин, – дип фаразлый министр.

Марат Садыйков бу урында Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашконың күрсәтмәсен дә искә алды. Хәтерләсәгез, төбәкләргә ким дигәндә дүрт айга җитәрлек дару запасы булдырырга кушкан иде ул. Мурашко моны чит илдән дару керткәндә тоткарлыклар булу белән аңлатты.

– Даруларга гына түгел, медицина җиһазларына да кагыла бу. Бүген без аларны кайтартуның башка юлларын да таптык. Бүген аларның күп өлеше Кытай белән Төркиядән кертелә. Республика компьютер томографиясе уздыру өчен кирәкле, Кытайда җитештерелгән югары технологияле җиһаз кайтарту мөмкинлеген биргән бәйгедә җиңде. Бу җиһазлар ел дәвамында эшли инде. Аларны кулланганда бернинди җитешсезлек, авырлыклар белән дә очрашмадык. Алар Европада җитештерелгән җиһазларга караганда да яхшырак эшли дип әйтә алам, – ди министр.

Күчмә сырхауханә

Татарстанда районнарга йөри торган тагын бер күчмә сырхауханә комплексы пәйда булачак. Министр сүзләренә караганда, район, авыл җирлекләрендә яшәүчеләр каладан килгән мондый тәгәрмәчле сырхауханәләрне көтеп ала. Ел башыннан бирле алар 24 районда яшәүче 25 мең кешегә хезмәт күрсәткәннәр. Әлеге төр тикшеренү барышында 3 мең кешедә беренче тапкыр авыру табылган.

– Әлеге төр медицина ярдәме 2019 елдан бирле гамәлдә. Якын арада тагын бер күчмә комплекс сатып алыначак. Шул рәвешле районнарга барлыгы биш күчмә сырхауханә машинасы йөриячәк. Алар район җитәкчелеге һәм район хастаханәсе баш табиблары белән килештерелгән график буенча киләчәк, – дип ачыклык кертте министр.

Ахыры 2 нче биттә >

Эшле кеше – көчле кеше

Ноябрь аенда Татарстанда эшсезләр саны кимү күзәтелә. Мәшгульлек күрсәткече – тулаем Россия буенча уртача саннан югарырак дәрәҗәдә. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, республикада бу күрсәткеч – 62,6% (ил буенча уртача – 60, Идел буе федераль округы буенча – 59,5%).

Тугыз айда эшсезләр эшләүчеләрнең гомуми санының 2,3 процентын тәшкил иткән. Соңгы елларда иң кечкенә күрсәткеч бу. Ел башына мәшгульлек үзәкләренә барлыгы 62,3 мең кеше эш эзләп барган. Шуның 40 меңенә (мөрәҗәгать итүчеләрнең 64,2 проценты) хезмәт урынын табуга ирешелгән.

Ноябрь урталарына мәшгульлек үзәкләрендә теркәлгән эшсезләр саны, гыйнвар ае белән чагыштырганда 2,7 меңгә кимеп, 8,6 мең кешегә калган.

Чирләмә!

Илнең 55 төбәгендә, шул исәптән Татарстанда дуңгыз гриппын йоктыру очраклары теркәлгән. Гриппның башка вируслары арасында нәкъ менә шул өстенлек итә. Биредә сүз A(H1N1) штаммы турында бара. Исегезгә төшерәбез: дуңгыз гриппы – кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авыру. Гриппның әлеге куркыныч төре беренче тапкыр 2009 елның апрелендә табылган.

Роспотребнадзор мәгълүматларына караганда, ОРВИ һәм грипп йоктыручылар саны бер атна эчендә алдагысы белән чагыштырганда 18,5 процентка арткан. Шул ук вакытта 43 төбәкнең күрсәткече Россиядәге уртача күрсәткечтән артып киткән. Моннан тыш коронавирус белән чирләүчеләр саны да ишәя. Соңгы атнада чир йоктыруның 39 мең очрагы теркәлгән. Бу – алдагы атна күрсәткеченнән 7 процентка зуррак сан.

Тылсымлы поезд килә

5 декабрьдә «Казан-1» тимер юл вокзалына Кыш бабайның тылсымлы поезды – күчмә резиденциясе килеп җитәчәк. Шәһәрдә яшәүчеләр бәйрәмчә бизәлгән поездны кичке дүртенче яртылар тирәсендә каршыларга җыена.

Ул 19 вагоннан тора. Аларда кабул итү бүлмәсе, сәхнә, уеннар һәм квестлар өчен «Әкият авылы», ресторан, сувенирлар кибете булдырылган. Вагоннары гирлянда белән бизәлгән паровоз артыннан теркелде.

Кыш бабай поезды янында бәйрәм булачак. Керү – бушлай. Кунаклар проект сайтында алдан сатып алынган билетлар буенча кабул ителәчәк.

Кыш бабай 22 октябрьдә Великий Устюг шәһәреннән ил буйлап сәяхәткә кузгалган. Поезд ил буенча 33 мең чакрым юл үтәчәк. Ул шулай ук Ижау, Йошкар-Ола шәһәрләрендә тукталыш ясарга ниятли.

Чын кышка керәбез

Гидрометеоүзәк белгечләре декабрь башында һава торышының ничек булачагын әйткән. Татарстанда кышның беренче көнендә, дөресрәге, төнендә 17 градуска кадәр суыта. Көндез –12 градус булачак. Явым-төшем көтелми.

Синоптиклар мәгълүматларына караганда, җомга һәм шимбә – 2–3 декабрьдә көндез һава температурасының –7…–12 градус чикләрендә тирбәлүе фаразлана. Төнлә температура 19 градуска кадәр төшәчәк. Җомга көнне явым-төшем көтелми. Шимбәдә кайбер районнарда кар яварга мөмкин.

Белми калмагыз!

Декабрь үзгәрешләре

Декабрь аенда керәчәк үзгәрешләрне барлап, иң әһәмиятлеләрен тәкъдим итәбез.

✓**Медицина полисы штрихкодка әйләнә.** Хастаханә-сырхауханәләрдә кәгазьдәге Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе (ОМС) полисларын күрсәтергә кирәк булмаячак: бу документ цифрлаша. ОМС системасында иминиятләштерелгән һәр кешегә код бирелә. Кодтан торган документны смартфонда саклау мөмкин.

✓**Чит ил агентлары өчен яңа чикләүләр.** Аларга дәүләт һәм муниципаль оешмаларда укыту, иҗади проектларына дәүләттән ярдәм сорау, гадиләштерелгән салым салу системасыннан файдалану тыела. Чит ил агентлары эштә үз статусы турында белдерергә, нәшер ителүче материалларын «иноагент» дип тамгаларга тиеш.

✓**Торак-коммуналь хезмәтләр 9 процентка кыйммәтләнә.** Әмма бу – максималь сан. Тәгаен күпмегә арттыру мәсьәләсен төбәк хакимияте хәл итәргә тиеш. Салкын һәм кайнар су, электр энергиясе, җылылык, газ һәм чүп чыгару бәяләре үсәчәк. Икътисади үсеш министрлыгында исәпләп чыгаруларынча, 1 декабрьдән өч кешелек гаиләдә ТКХ өчен түләү аена уртача 324 сумга артачак.

✓**Банкларга – киртәләр.** Беренчедән, кредит килешүен төзегәндә «тагылган» өстәмә хезмәтләрдән (әйтик, юрист ярдәме яисә консультация) 14 көн эчендә баш тартып булачак. Кредитны иминиятләштерү буенча байтактан шулай бу. Ләкин башка хезмәтләрдән баш тарту авыррак иде әле. Икенчедән, банк хезмәткәренә кредит килешүен «каргачык» белән тамгалау, шуңа гына күрсәтеп, кул куйдырту тыела. Кредит алучы килешү шартларын укып чыкканнан соң гына, ризалыгын раслап, имза салырга тиеш.

✓**Фатирларда хаммам урнаштырырга мөмкин.** Күпфатирлы яңа йортларда хаммам һәм солярий булдыру мөмкинлеге ачыла. Шул ук вакытта мунча һәм сауналар ясау, элеккечә үк, тыела.

✓**Финанс пирамидаларына каршы көрәш.** Кешеләрне финанс пирамидаларына тартып кертүче – акчаларын суырып алганнан соң юкка чыгучы сайтларны судсыз-нисез ябу мөмкинлеге ачыла.

✓**Тамгаланмаган продукция саткан өчен җаваплылык.** Товарларны, шул исәптән даруларны маркировкалау таләбен бозган өчен административ җаваплылык кертелә. Шул ук вакытта продукцияне ялган тамгадан файдаланып җитештергән, саткан, саклаган өчен җинаять җаваплылыгы каралган.

✓**Чит илдән килүчеләрдән бармак эзләрен мәҗбүри алу һәм аларга медицина тикшерүе уздыру.** Россиягә 90 көннән күбрәк вакытка килүче чит ил кешеләреннән бармак эзләре алынырга һәм медицина тикшерүе уздырылырга тиеш. Аларның ВИЧ-инфекция һәм башка йогышлы авырулары, шулай ук наркотикларга бәйлелектән азат булу-булмавы тикшереләчәк. Бу гамәлләр Россиягә кергәннән соң – 90 көн, ә эшкә килүчеләргә 30 көн эчендә башкарылырга тиеш.

✓**Әйләнә-тирә мохитне саклау.** Һавага төтен-газ чыгаруны чикләү чаралары гамәлгә кертелә. Алар дәүләт исәбенә алыначак, кимету күрсәткечләре билгеләнәчәк, шулай ук киметүгә ярдәм ителәчәк.

Сүзгә-сүз

wciom.ru

Валерий ФЕДОРОВ, Илкүләм җәмагатьчелек фикерен өйрәнү үзәге башлыгы:

Минем иң яраткан сораштыруым – бәхет турында сораштыру. 1991 елдан башлап елына ике тапкыр без ил халкыннан «Сез бәхетлеме яки юкмы?» дип сорыйбыз. 1990 нчы елларда барысы да начар иде, ләкин тормыш тәртипкә килгәч, бәхет күрсәткече артты. Соңгы елларда россиялеләрнең 80 проценттан артыгы бәхетле булуын әйтә.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

«РИА-Новости» агентлыгы Россия төбәкләрендәге халыкның сәламәт яшәү рәвешенә мөнәсәбәтен тикшергән. Бишенче ел рәттән әлеге рейтингның лидерлары булып Россиянең көньяк төбәкләре танылган.

1 >> Дагыстан	…
2 >> Чечня	30 >> Әстерхан
3 >> Адыгея	**31 >> Татарстан**
…	…
12 >> Мари Иле	85 >> Еврей автономияле округы

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **980 сум 10 тиен**, гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ГАЗЛАЙТИНГ» ЕЛ СҮЗЕНӘ ӘЙЛӘНГӘНДӘ

Безнең күзәтүләрне укып баручылар, бәлки, хәтерли торгандыр: үткән атнада без: «Цифрлы валюталарга бәйле фирмаларның түнтәрелеше алда торган кризисның төп давыл хәбәрчесе булырга охшаган», – дигән юл язган идек. Без андый фаразларда сирәк ялгышабыз. FTX криптобиржасының банкротлыгы чылбыр реакциясе башлап җибәреп ята. ААХ криптобиржасының хәле яман. 13 ноябрьдә ул барлык операцияләрне туктаткан, әмма 7–10 көннән соң эшен башлап җибәрергә вәгъдә иткән иде. Ике атнадан артык вакыт үтеп бара. Биржада тынлык. Алай гына да түгел, ул Youtubeтагы үзенең рәсми каналын юк итте, Facebookтагы аккаунтын бетерде. Аның вице-президенты Бен Каселин компанияне ташлап китте. Гади обыватель өчен бу сүзләр берни хакында да сөйләми, билгеле. Әмма ААХның бу гамәлләреннән 2 миллион клиент зыян күрде, алар арасында россиялеләр һәм БДБ илләре вәкилләре дә күп. Күз алдыгызга китерегез әле: һәр клиент мең доллар гына югалтса да, ике миллиард доллар куыктан чыгып очты дигән сүз. Ә бит криптовалюталарга миллионнарны тыккан клиентлар байтак. Безнең кебек фәкыйрьләр алар белән кызыксынмый да, андый биржаларда байлар акча җилгәрә. Без алар өчен алай кайгырмыйбыз, әлбәттә, әмма табигый байлыклар, чимал сатып тупланган акча иртәнге томан кебек юкка чыга. Аларны реаль икътисадка тыгарга, эш урыннары булдырырга, сүнеп барган икътисадны кабызып җибәрергә мөмкин иде. Әмма моның урынына бөлгенлек килә, олигархлар суган суы суыра башлаганда, ачысы безнең күзләрдән дә яшь чыгара.

ААХ Гонконг криптобиржасы иде. Сишәмбе таңында, төгәлрәк итеп әйтсәк, 5 сәгать 36 минутта бу юлларның авторы: «АКШтагы BlockFi криптобиржасы банкротлыкка гариза бирде», – дигән хәбәр алды. Исегезгә төшерәм: үткән җомга санында гына без: «Биржасы түнтәрелеп, мошенник икәне киң катлауга мәгълүм булгач, Бэнкман-Фрид турында BlockFi директорларының берсе: «Сэм Бэнкман-Фрид ботаник битлеге кигән иблис иде», – дип язып чыкты», – дигән юллар китергән идек. Җан ачысы белән әйткән инде ул сүзләрне, чөнки FTX криптобиржасында аның бик күп байлыгы янган. Нәкъ менә шуның турыдан-туры нәтиҗәсе буларак, BlockFi да мәтәлчек ата. Чылбыр реакциясенең ни икәнен әйбәт аңлата безгә бу хәлләр. Криптобиржа хуҗалары бер-берсенең токеннарын актив сатып алалар, үзара финанслау көчле бара. Шуңа күрә биржа түнгәндә, домино эффекты китереп чыгара. Алар шулай үзара гына егылышсалар, без кайгырмас та идек, әмма үз артларыннан глобаль икътисадны сөйриләр. Хәер, соңгысында болай да мошенниклык, күз буяу тулып ята, банкротлыкның чылбыр реакциясе бар тарафларда да башланып килә. Америка телевидениесе сишәмбегә каршы төндә «газлайтинг» дигән сүзнең ел сүзенә әйләнүен хәбәр итте. Әле яңа гына инглиз теленә килеп кергән ул сүз «үзеңә файда алу өчен кемнедер тупас рәвештә адаштыру гамәле» дигәнне аңлата икән. Халык эзләү системаларыннан актив рәвештә шул сүзнең мәгънәсен эзли, димәк, кешеләр спекулянтлар тарафыннан үзләренең рәхимсез рәвештә алдануларын аңлый башлаганнар.

Россиядә

ХӘБӘРЛӘР АРТЫНДА НИ БАР?

Россия мәгълүмат каналларының баш исемнәрен укыганда, мин бер нәрсәгә игътибар итәм: бездә көнбатышлыларның авыр хәленә сөенү тулып ята. Әйтик, бер аналитик журнал «У Европы начинается газовый насморк» дигән сарказм белән тулы баш астында мәкалә бирә. Көннәр суытыр да газга бәя күтәрелер, көнбатышлылар безнең алга килеп тезләнерләр дигән эчке бер яшерен куаныч сизелә ул сүзләрдә. Дошманнарның борынына томау төшкәндә, шатланмый түзеп булмый шикелле. Әмма теге як сер бирми: Россия газын алуны минимумга калдырды, газ саклагычларын тутырып куйды да, кыйммәтле чималны сак кына тота. Башка базарлардан ягулык эзли. Австралиянең «Woodside Energy Group» компаниясе соңгы көннәрдә генә немец энергетик гиганты «Uniper»га газ тутырылган беренче танкерын озатты. Безнең бер генә сөенеч кала: ерактан килгән газ кыйммәткә төшә. Ярый, хуш, шулай булсын, ди, интексеннәр немецлар, безнең газдан баш тартуның ачысын татысыннар. Әмма глобаль икътисад шулай корылган: берәүнең борынына томау төшсә, вирусы сиңа да эләгә. Энергия чыганакларына бәя күтәрелү икътисад кризисын көчәйтә. Һәм тизләтә дә. Болайрак фикерләп карыйбыз әйдә: бөлгән Европада товарларга, бигрәк тә чит ил товарларына ихтыяҗ кими. Өстеңә кат-кат свитер кигәндә, Кытайда җитештерелгән айфоннар белән бик уйныйсы килми. Көнбатыш базары исә – кытайлар өчен төп базар. Ул базар кысылганда, Кытай икътисады да котылгысыз рәвештә кысыла. Алар исә – нефтьне иң күп кулланучы дәүләт. «Кара алтын» сатып алуны (шулай ук газ сатып алуны да) кытайлар киметәләр. Нефтькә бәяләрнең, бигрәк тә Россия нефтенә бәяләрнең кискен төшеп баруын күрәсездер. Без тагын шатланабыз: ОПЕК+ декабрь башындагы утырышында «кара алтын» чыгаруны яңадан киметергә җыена дигән баш астында дәртле язмалар бастырабыз. Болай да аз кулланыла башлаган нефтьнең бәясе шул сәбәпле күтәрелә икән, ул кризисның көчәюенә өстәмә сәбәп кенә була. Бәя тагын төшә, чыгаруны тагын киметергә кирәк була. Россия «кара алтын» ятмаларын бер томалап куйдыңмы, яңадан эшкә җигү кыен була. Бик зур акча тотып тагын нефть кудыра башласаң да, үзкыйммәт арту сәбәпле, табышка урын калмый. Көнбатышка карап елмаеп күпме генә бумеранглар атсак та, алар көнчыгыштан әйләнеп килеп, безнең арткы якка сылыйлар ягъни.

«Российская газета»ның «Банки начали активно брать в долг у ЦБ» дигән мәкаләдән бик күп нәрсә укыйм мин үзем. Язмада бер нәрсә турында сүз бара, ә юл арасыннан бөтенләй башка мәгънәләр дә укырга була. Банклар бурычка акчаны ОФЗ сатып алу өчен сорый. Бу бюджетның хәле начар икәнен аңлата һәм зур инфляция вәгъдә итә. Уйлап карасаң, чынлыкта, көнбатышлылар борынына төшкән томау безнекен дә томалый. Икенчедән, банкларның хәле шәп түгел дигән мәгънә дә килеп чыга. Алардан валюта кача, мәсәлән. Ел башыннан валюта депозитлары 40 процентка кимегән. Бу депозитта торган акчаның куркыныч астында икәнен дә сөйли. Сөенергәме, юкмы, анысын үзегез хәл итегез.

АҢЛАШЫРГА КҮП КИРӘКМИ

Тел, мәдәният кенә түгел, сәнәгать тә аңлашырга булыша. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шушы көннәрдә Азәрбайҗанга эш сәфәре белән килде. Бакуда ул республика Президенты Илһам Алиев белән очрашты. Моннан тыш ватандашлар белән сөйләштеләр, ике республика өчен дә үсеш юлларын барладылар.

tatarstan.ru

Татарстан Президенты искәрткәнчә, быел биредә республиканың вәкиллеге оешуга – 30 ел. «Без мәдәният ягыннан бик якын, телләр охшаш, бу инде безгә бер-беребезне яхшырак аңларга ярдәм итә. Хөрмәтле Президент белән сәүдә әйләнешен арттыру турында килештек», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Саннарга игътибар итсәк, 2021 елда Татарстан һәм Азәрбайҗан арасындагы товар әйләнеше 70 млн доллардан артып киткән. Ә инде 2022 елның беренче яртыеллыгында гына да саннар 2 тапкыр артыграк.

– Россия белән Азәрбайҗан арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга юнәлдерелгән ике республика арасындагы багланышларны үстерүгә игътибарыгыз өчен рәхмәтемне җиткерәм, – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән. – Без, әлбәттә, җиңел чорда яшәмибез. Кайбер Көнбатыш партнерларыбыз безнең белән араны өзде. Татарлар һәм азәрбайҗаннар туган булдылар һәм булып калачаклар да. Без бу төбәкнең бизнесы Россиядә дә үсеш алуын телибез. Бурычлар күп.

Рөстәм Миңнеханов очрашу вакытында ике республика арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү гамәлдә булуын искәртте. Моннан тыш, хөкүмәтара комиссия дә гамәлдә. «Безгә Идел-Каспий бассейнының транспорт һәм логистика мөмкинлекләреннән активрак файдаланырга кирәк», – дип ассызыклады республика җитәкчесе.

Хезмәттәшлек өлкәсендә ул энергетика һәм сәнәгать, автомобиль төзелеше, нефть химиясе, газ-моторлы ягулык кебек юнәлешләрне аерым билгеләп үтте. Зур завод-предприятиеләрнең дә мөмкинлекләрен сынап карарга җирлек бар.

Илһам Алиев та Татарстан белән Азәрбайҗан арасында тарихи элемтәләр барлыгын телгә алды. «Ике тапкыр сездә кунак булдым. Бу сәфәрләремне җылылык белән искә алам», – диде ул.

Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов Азәрбайҗанга эш сәфәре кысасында эшлекле форумда да катнаша. Бирегә ике якның да предприятие, бизнес вәкилләре дә чакырулы иде. Республика Президенты искәрткәнчә, хезмәттәшлекне арттыру өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Очрашу азагында ике дәүләт арасындагы хезмәттәшлек турында имзаланган документлар да моны дәлилли.

Азәрбайҗан Премьер-министры урынбасары Шахахин Абдулла оглы Мостафаев әйтүенчә, Татарстан икътисади партнерлар арасында лаеклы урынны алып тора. «Азәрбайҗан белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләр стратегик характерга ия һәм барлык тармакларны колачлый. Төбәкара элемтәләр – безнең өчен өстенлекле юнәлеш. Ел нәтиҗәләре буенча, ике арадагы товар әйләнеше дә бермәбер артыр дип өметләнәбез», – диде вице-премьер.

Сезгә мөнәсәбәт тә башка. Татарстан Президенты белән очрашу вакытында Азәрбайҗан Премьер-министры Али Идаят оглы Асадов шулай диде.

– Без сезнең килүегезгә шатбыз, – диде ул. – Берничә көн элек Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин да Азәрбайҗанга килеп китте. Очрашуларда төбәкара хезмәттәшлек турында сөйләштек. Без Татарстанның Россиядәге алдынгы республика икәнен беләбез. Сезгә Азәрбайҗанда мөнәсәбәт тә башка, хөрмәт белән карыйлар.

Үз чиратында республика җитәкчесе аңа очрашу оештырган өчен рәхмәтен җиткерде.

– Рух, тел, мәдәният ягыннан якын булган төбәккә килүемә шатмын. Безнең республикалар арасындагы җылы мөнәсәбәтләр сезнең Президент Гейдар Алиев һәм безнең беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең шәхси дуслыгы бәрабәренә туды. Безгә дә бу мирасны сакларга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Саклар һәм сакланыр чак

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Уникаль операция

Узган атнада республикада тагын бер уникаль операция ясауга керешкәннәр. Республика клиник балалар хастаханәсе базасында эшләүче Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә арка миен күчереп утырту буенча беренче катлаулы операция ясалган. Әлеге үзәк узган елның июнендә ачылган иде.

– Узган атнада без балага арка миен күчереп утыртудан гыйбарәт булган катлаулы операция ясый башладык. Республиканың сәламәтлек саклау тармагы тарихында беренче очрак бу. Без Дмитрий Рогачев исемендәге балалар гематологиясе, онкология һәм иммунология тикшерену үзәге белән берлектә эшлибез. Трансплантация уңышлы узар дип ышанам, – диде министр.

Марат Садыйков сүзләреннән аңлашылганча, бавыр, бөер һәм йөрәк күчереп утыртудан аермалы буларак, арка миен күчереп утырту бер көндә генә башкарыла торган операция түгел. Аның өчен шактый вакыт таләп ителә. «Бу юнәлештә үз урыныбызны табып, федераль үзәк белән бергәләп эшләрбез дип уйлыйм», – диде министр.

Бала тудыру йортлары

Татарстанның сәламәтлек саклау министры Спас Үзәк район хастаханәсендә эшләп килгән бала тудыру йортының ни сәбәпле ябылуын да аңлатты. Марат Садыйков сүзләренә караганда, бала тудыру йортын ябу-япмау мәсьәләсе хәл ителгәндә, иң элек биредә елына күпме бала тууга игътибар итәләр.

– Спас буенча төгәл әйтә алмыйм. Әмма елына якынча 80ләп бала тудыру очрагы гына теркәлә икән, бу инде дөрес түгел. Монда акушер-гинекологның һөнәри осталыгы да, квалификация мәсьәләсе дә зур роль уйный. Аннары хәзер бөтен ил күләмендә кечкенә җирлекләрдәге бала тудыру йортларын ябу күзәтелә. Биредә эш күләме җитәрлек дәрәҗәдә булмауга да игътибар итәләр. Кызганыч, андый бала тудыру йортларында аналар арасында үлем-китем очраклары да күзәтелә. Кайбер төбәкләрдә андый бала тудыру йортлары ябылды инде. Аларга икенчел дәрәҗәдәге, ягъни районара бала тудыру йортлары алмашка килде, – диде Марат Садыйков.

Министр сүзләренчә, аз куәтле балалар тудыру йортларын калдыру яки башка төрле итеп үзгәртү күздә тотыла. Әлегә төгәл хәл ителмәгән. «Авыр хәлләр килеп чыкмасын өчен, хатын-кызлар консультациясе бөтенләй башка дәрәҗәдә төзелергә тиеш. Катлаулы очракларга, өзлегүләргә юлыккан хатын-кызлар иң югары яки өченче дәрәҗәдәге бала тудыру йортларында дәваланырга тиеш», – диде Марат Садыйков.

ВАТАНПӘРВӘРЛЕКНЕҢ НИГЕЗЕ

Патриотик тәрбия дәүләт символларына хөрмәттән башлана. Казан федераль университетында Президент каршындагы Геральдика советы әгъзалары белән узган очрашуда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әнә шулай диде.

Президент каршындагы Геральдика советы оешуга быел – 20 ел. Совет әгъзалары белән очрашуда парламент башлыгы советның ТАССР төзелүнең 100 еллыгы, ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кебек әһәмиятле юбилейларны оештыруга зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

– Өч дистә ел эчендә илебезнең Геральдика хезмәте бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда шактый зур юл үтте. Сез дәүләтнең тарихи үткәненә, аның мәдәниятенә карата җәмәгатьчелек кызыксынуын арттыруга, патриотлык хисе, рәсми символларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштырасыз, – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин ассызыклаганча, рәсми символлар Россия халыкларының тарихи-мәдәни мирасын тәшкил итә.

– Советлар Союзы таркалган елларда без күпмилләтле халкыбызны берләштерү, илнең, республиканың патриотларын тәрбияли алырлык символлар барлыкка китерү турында уйландык. Иҗтимагый-сәяси тормышта геральдиканың әһәмияте бәяләп бетергесез. Символларсыз, геральдикасыз халыкны берләштерү һәм аларда ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү кыен булыр иде. Гражданнарның патриотик үзаңын формалаштыру нәкъ менә дәүләт символикасына хөрмәттән башлана, – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, флаг, герб, гимн һәрвакыт Россия дәүләте халыкларын берләштерде һәм Ватан хакына батырлыкларга илһамландырды. – Бүгенге шартларда безнең ил моңа беркайчан да булмаган кебек мохтаҗ, – диде ул.

Мәктәпләрдә һәр яңа уку атнасы ил һәм республика байракларын күтәрү һәм гимннарын җырлау белән башлануны да Фәрит Мөхәммәтшин яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүнең нәтиҗәле чарасы дип әйтте.

– Гимннарны җырлап, байракларны күтәреп, яшьләребезне берләштерәбез, аларның патриотик рухларын күтәрәбез. Атна башында үткәрелә торган «Мөһим сөйләшү» аша иң четерекле сораулар турында фикер алышабыз. Тарихны белү, үз илебез, республикабыз символларына хөрмәт белән карау яшьләрдә Ватанга карата мәхәббәт уята, – диде парламент башлыгы.

Очрашу ахырында Фәрит Мөхәммәтшин дәүләт бүләкләрен тапшырды. «Дуслык» ордены белән – Татарстан Президенты каршындагы Геральдика советы рәисе Рамил Хәйретдинов, «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән Татарстан Фәннәр академиясенең Мәрҗани исемендәге Тарих институты рәисе Радик Салихов һәм башкалар бүләкләнде.

Ләйсән САФИНА

ЭЛЕКТРОН БУЛСА ДА, АКЧА

Яшәеш

Республикада яшәүче физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр күп кенә проблемалар белән очраша. Безгә мөрәҗәгать иткән кешеләрнең күбесе подгузниклар, үзләренә кирәкле тернәкләндерү чаралары ала алмауга зарлана. Сораугa җавап эзли башласаң, йә аның әлегә юклыгы, йә хезмәт күрсәтергә тиешле оешманың эшенә салкын каравы ачыклана. Ә физик мөмкинлеге чикләнгән кеше нишләсен?

«Татар-информ»

Баксаң, хәзер кешеләр үзләренә кирәкле барлык тернәкләндерү чараларын интернет аша сатып ала икән. Моның өчен аларның һәркайсына үзенә тиешле суммада электрон сертификат бирелә. Бу хакта Россия Социаль иминият фондының Татарстан буенча төбәк бүлеге идарәчесе Фердинант Закиров сөйләде.

– 2022 елда инвалидларга тернәкләндерү чаралары алу өчен федераль бюджеттан 1,5 млрд сум акча бүленеп бирелде. Шуның 210 миллион сумы ял йортларына бару өчен юлламага тотылды. Быел дәүләт контрактын үтәү җиңел булмады. Май аенда 23 сум торган подгузникның бәясе 89 сумга күтәрелде. Безгә күп кенә товар кайтаручылар белән килешүне өзәргә туры килде. Кешеләрнең озак вакыт товар көтүләре дә шуңа бәйле. Намуссыз эшмәкәрләр корсет кайтаручылар арасында да бар иде. Эшенә салкын караучыларның барысы белән дә хушлаштык, – ди Фердинант Закиров.

Әле күпләр белмидер дә: хәзер үзеңә кирәк-яракны электрон сертификат белән алып була. Ул сертификат һәр физик мөмкинлеге чикләнгән кешегә шәхси тернәкләндерү программасына нигезләнеп бирелә. Кешенең үзенә кирәк әйберне сайлап алу мөмкинлеге арта. Сайт аша алганда, ул үзенә ошаган товарны сайлый. Түләү исә шушы сертификат ярдәмендә башкарыла. Әлегә кадәр бу электрон сертификатның ни икәнен, аны кая барып аласын да белмәүчеләр бар икән. Фердинант Закиров аңлатуынча, республиканың һәр районында урнашкан социаль иминият фондларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әмма аеруча өлкән яшьтәге кешеләр бу яңалыкка шикләнеп карый икән. Күбесе тернәкләндерү чаралары сатучы оешмаларга килеп, үз акчасына сатып ала. Мондый очракта исә алар товарлары өчен дәүләттән компенсация алырга хокуклы.

Аңлату – бер хәл, интернет аша сайлаган товарны авыл кешесе кая килеп алсын? «Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар арасында шушы сорауны да бирүче булды. Дөрестән дә, үзенә кирәкле таяк, аяк киеме, колак аппараты алыр өчен кешегә күпме юл үтәргә кирәк. Тернәкләндерү чараларын бирергә хокуклары булган һәм электрон сертификат белән эшләүче оешмаларның күбесе Казан шәһәрендә урнашкан. Белгечләр бу хакта да, эшләп бетерергә кирәк, диештеләр. Алар өчен халыкның электрон сертификатны алуы мөһим. Аның икенче ягы да бар икән. Баксаң, колак аппараты алырга килүче әниләр балаларына олы кешеләр куллана торганын сайларга мәҗбүр. Чөнки башкасы юк. Шуңа алар тумыштан ишетү сәләтеннән мәхрүм булганнар өчен аерым аппарат эшләүләрен сорыйлар. Бу сорауга Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкиле, балага колак аппаратын әтиәни түгел, табиб сайлый, дип, җавапны кыска тотты. Нинди аппарат кирәген табиб белән хәл итәргә киңәш итте.

Очрашуга килүчеләр арасында электрон сертификат белән тернәкләндерү чарасы алырга тырышып караган кеше дә булды. Интернет аша үзеңә кирәкле әйберне сайлау тиз, әмма аның ничә сум, кая барып аласын язмаганнар. Элемтә өчен телефон номеры да юк икән.

Фердинант Закиров бу эшнең күптән түгел генә башланып китүен, кимчелекләрнең бетереләчәген әйтте. Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне исә яңа хезмәтне кулланырга курыкмаска чакырды.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ИКЕ ДӨНЬЯ АРАСЫ

Ул эшкә зиратка йөри. Юк, кабер казучы түгел, язмамның герое – мәрхүмнәрнең истәлегенә соңгы сүзләрне язучы. Питрәч районының Шәле авылында яшәүче Равил абый Ногмановның һөнәре әнә шундый бакый дөньяны гел искә төшерә торганнардан. Шуңа күрәдерме, тормышның кадерен белә. Хыялы – 120 яшькә җитү. Үзенә шулай дип вәгъдә биргән икән.

Зиратта эшләгәч, бик җитди, аз сүзле кеше дип күз алдына китергән идек Равил абыйны. Ялгышканбыз, шат күңелле булып чыкты ул. Гамәлләре дә, яшәү рәвеше дә сокланырлык. Хатыны Аэлита белән 37 ел яшәп, бер тапкыр да ачуланышканнары юк икән. Аэлита – татар кызы, иреннән ун яшькә яшьрәк. Гаилә башлыгына – 64 яшь. Шәлегә шәһәрдән күченеп кайткан Равил абый үз куллары белән яңа йорт төзегән. Авылдашлары ярдәм итәргә теләсә дә, «юк, үзем» дип, кырт кискән. Эштән кайткач, фонарь яндырып, шуның яктысында кирпеч өйгән. Моның өчен 4 ел вакыты киткән. Күршеләре шәһәр егетенең булдыклылыгына шаккаткан. Шаккатарлык шул ул!

– Казаннан күченеп кайтуыбызга 30 еллап үтте. Кечкенә чакта Саба районының Байкал авылына кунакка кайта идем. Авылны бик яратам. Шуңа күрә, шәһәргә ерак түгел дип, Шәлене сайладык. Моннан беркая да китәсе килми. Авылда да эш бар, тырышырга гына кирәк, – ди Равил әфәнде.

Шәһәрдә яшәгәндә портретлар, картиналар иҗат иткән. Кулына пумала тота белгәч, 1983 елда кабер ташларына язып сынап караган. Менә шуннан бирле бу эшен ташламый. Хәзерге вакытта Курган, Киндери зиратларында эшли.

– Зиратка эшкә йөрү күңелгә авыр, әлбәттә. Кайда җиңел соң? Әрвахлардан куркырга кирәкми. Эшне бисмилла әйтеп башлыйм. Хезмәт белән барысы да оныткыла. 100–200 килолы ташларны күтәрергә туры килә. Улым Камил белән көнгә 10–15 ташка язабыз. Заказ булуга чакырып торалар. Кулдан язсаң, бер ташка – 2–3, станок белән бер сәгать вакыт китә, – ди әңгәмәдәшем.

Равил абый сәламәт яшәү рәвеше алып бара. Эчми, тартмый. 12 яшьтән спорт белән шөгыльләнә. Хәзер дә штанга күтәрә, скандинавча йөри, йөгерә. Тик аягын авырттырганнан бирле артыгын куа алмый икән. Җайлап, түмен белеп кенә йөри. Кайчан иртән сәгать 4тә үк чыгып китә икән басуга. Сәгать 8гә эшкә барып җитешәсе бар чөнки. Көн саен 15 чакрым җәяү йөрергә тырыша. Заманасында марафоннарда да катнашкан. 21 чакрымны 1 сәгать 43 минут эчендә үткән.

– Дару эчкәнем юк. Бөтен начар энергия тир белән чыга. Эштә тузан сулыйм бит, аны ничек тә булса чыгарырга кирәк. Йөгергәч, үпкәләр киңәеп китә, сулыш алулары җиңеләя. Яшьләргә дә, йөгерегез, хәрәкәтләнегез, диванда гына ятмагыз, дим, – ди Равил ага. – Яшьләр күп үлә шул, ирләр хәтта 60 яшькә дә җитми, кызганыч. Шул ук вакытта елга берничә тапкыр 100 яшькә җитүчеләр истәлегенә дә ташлар язгалыйм. Юк, мин әйтәм, минем күбрәк яшисем килә, дим. Тормышны, хатынымны, балаларымны яратам. Безнең нәсел озын гомерле, 80–90 яшькә җитүчеләр дә бар.

Хатыным белән ачуланышкан юк, диде бит. Моның серен дә белдек.

– Аэлитага – 54 яшь. Тик аңа күпләр үз яшен бирми, 35 кенәдер дип уйлыйлар. Андыйларга: «Әйе, яшь күренә, ире яхшы бит аның», – дип шаяртам. Бүләген дә бирәм. Хатын-кыз өчен күп кирәкмени? Бер җылы сүз җитә. Әгәр беребез кызып китә башласа, икенчебез «тынычлан» дип, башка бүлмәгә чыгып китә. Менә шулай гаиләдә татулыкны, ярату хисен саклыйбыз. Яшьләрне дә бер-берсен хөрмәт итәргә өйрәтәсе иде, – ди Равил абый Ногманов.

Сәрия МИФТАХОВА

«НЕЧКӘБИЛ»НЕҢ АЛТЫНЫ

Бәйгедән соң

Республикада узган бәйгеләр арасында күңелгә иң якыны «Нечкәбил»дер. Биредә бил нечкәлеге дә, матурлык та беренче урында түгел. Монда гаилә җылысын саклаган, бәхетле яшәүнең серен башкаларга да җиткерә алган кешеләр катнаша. Шушы көннәрдә бу бәйге 17 нче мәртәбә узды. Татарстанның төрле районнарында яшәүче финалга чыккан 12 гаиләдән иң-иңнәрен сайлап алдылар.

vk.com/nechkebil

Без «Алтын Нечкәбил» исемен яулаган Айгөл Һадиуллина белән гаиләдәге җылыны саклау серләре хакында сөйләштек.

Алар ире Рашат белән икесе дә – Алабуга районының Дөм-Дөм авылыннан. Ике өй аша гына яшәсәләр дә, башта алар бер-берләренә игътибар да итми. Ничек итәсең инде – Айгөл белән Рашатның яшь аермасы җиде ел бит! Кыз комлыкта уйнаганда, малай башлангычта укыган булып чыга түгелме соң? Әмма язмыш дигәнең үзенекен итә. Рашат Алабуга педагогика институтын тәмамлап, авылына укытырга кайткач, Айгөлгә күз ата. 11 нче сыйныфта укыган кызны бер кичәдән соң укытучы абыйсы озата кайта.

– Мин кечкенәдән Рашатның сеңлесе белән дус булдым. Бергә уйный идек. Аның әбисе безнең күрше булгач, Рашат белән дә гел күрешә идек. Әмма арада нидер булыр, кайчандыр гаилә корып яшәрбез дип уйламадык та. Ә бит мин бәхетне Рашат белән таптым, – дип сөйли Айгөл.

Мәктәпне тәмамлагач, Айгөл татар теле укытучысы булырга хыяллана. Әмма Рашат аны математиканы сайларга күндерә. Шулай итеп кыз институтка укырга керә. Алар тагын 2 ел очраша әле. 3 курста укыганда Рашат сөйгәненә тәкъдим ясый. Айгөл ризалаша. Тормышларын түгәрәкләп, башта уллары Айзат, 3 елдан соң кызлары Айзилә туа.

– Кызымны тапкан елны кулыма диплом алдым. Балалар үстергәндә иремнең ярдәме зур булды. Ул әле дә гел булышырга гына тора. Безнең гаиләдә эшне хатынныкына йә ирнекенә бүлү юк. Шуңа күрә аңлашып яшибез, – ди Айгөл.

Баксаң, ире җил-яңгыр тидермәгән үзенә. Тикмәгә генә, яшь аралары җиде ел булган гаиләләрнең никахы бәхетле була, дип әйтмиләрдер. Һадиуллиннар – моның бер мисалы. Рашат Айгөлен үз ышыгында гына йөртә. Беркайчан авыр сүз әйтеп җанын телгәләми. Айгөл үзе дә иркә хатын булып яшәргә өйрәнгән. Хатын-кызлар үзләренә артык зур җаваплылык алмасын иде, ди ул.

– Ирем – тормыш терәгем. Өйдә төп сүзне ул әйтә. Мин үзем дә аның сүзеннән чыкмыйм. Ул – бик гадел, тыныч холыклы, аек акыллы кеше. Балалар белән уртак телне тиз таба. Ә мин исә кайчагында кызып та китәм, усалрак та. Шулай бер-беребезне тулыландырып яшибез инде, – ди ул.

Һадиуллиннарның тагын ике балалары бар. Уллары Фазылга – 14, кызлары Гөлсирингә 5 кенә яшь әле. Аны соңлап кына алып кайтканнар. Әмма хәзер, олыраклары буй җиткәч, Гөлсиринле булаларына сөенеп бетә алмыйлар икән.

– Мин аны 37 яшемдә алып кайттым. Өебезнең кояшы булыр дип кем уйлаган аны?! Шулкадәр җайлы бала, җырга-биюгә оста. Аңа карагач, бар борчулар оныттыла, – ди Айгөл.

Һадиуллиннар 2016 елда матур итеп салып чыккан йортларын калдырып, Алабугага күчкәннәр. Балаларның сәләтләре ачылсын, төрле түгәрәкләргә йөрсен өчен шулай эшләгәннәр. Авылда әти-әниләре бар. Үзләре һәр атна саен өйләренә кайтып йөриләр. Җәйләре шунда уза. Инде Һадиуллиннар онык та сөяргә өлгергән. Уллары Айзат, өйләнеп, Ижау шәһәрендә яши икән. Айгөлдән килен-каенана хәлләрен сораштык.

– Киленебезне бик якын итеп кабул иттек. Ул – әни, мин, кызым, дим. Көн саен шалтыратып хәлләребезне белешәбез. Матур яшәсеннәр. Әти-әнигә шул җитә, – ди ул.

Укытучыларның үз балаларына тәрбия бирергә вакытлары каламы? Алар кайчак өйдәгеләргә игътибар җитмәвен дә яшерми. Әмма сабыйларының йөзләренә кызыллык китермәсенә ышаналар. Икесе дә атнага 34әр сәгать укыталар. Өйләренә кичен арып-талып кайтып керәләр. Уллары ашарга да пешерә белә, кирәк булса, идән дә юалар. Кызлар исә ирләр эшеннән курыкмый. Айгөлнең үзе сыман.

Бәйгегә килгәндә, Һадиуллиннар җырга-моңга бик оста. Нәселләрендә укытучылар стажы – 190 ел, өстәвенә араларында уен коралларында уйнаучылар, аларны ясаучылар да бар. Авыл клубындагы бәйрәмнәрдә дә актив алар. «Нечкәбил» бәйгесендә катнашырга чакыргач, Айгөл бераз каушап калса да, Рашат ризалаша. Укытучы эшенең күп булуы да куркытмый аны. Мәктәптән кайталар да репетициягә йөгерәләр. Алабуга шәһәре данын яклау өчен күп тырышырга туры килә аларга. Башта ярымфиналда чыгыш ясыйлар, финалга үткәннәрен белгәч, тагын да яхшырак итеп әзерләнергә тотыналар. Күпләр бу бәйгедә ирләрен үгетләп катнаштырса, Рашат, финалга чыккач, Айгөленә үзе ярдәм итә. Финалда исә аларга туганнары, якыннары булыша.

– Без җиңәрбез димәгән идек. «Алтын Нечкәбил» дип игълан иткәч, ышанмадык. Җиңү – җиңелү түгел инде. Бик рәхәт хисләр кичерәбез. Гаиләбез шундый зур бәйгедә җиңгән икән, димәк, без дөрес юлда, – ди Айгөл. – Алга таба да булган бәхетебезне саклап, бер-беребезгә булган хисләрне кадерләп яшәсәк иде. Без – балаларга үрнәк. Алар безне кабатлый. Әнә шуны онытмаска кирәк. Без матур яшәсәк, алар да шулай яшәячәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы фикере

Дөньяда иң кирәк нәрсә...

«Дөньяда иң мөһим нәрсә – су!» – дип әйтсәм, бу беркемгә дә яңалык булмый инде. Аны барысы да белә. Тамак кипкән вакытлар бар, шунда берәр көрешкә салкын су эчеп җибәрсәң, оҗмах шушы икән дип торасың. Яки эссе челләдә печән чапкан арада салкын су белән коенып җибәрсәң...

Шәһәр автобусында одеколон, затлы хушбуй, дезодорант, перегар, суган, сарымсак, тир һәм башка адәми исләр арасында ысланып кайтып кергәннән соң душка кереп, су астына бассаң... Менә шундый чакларда суның кадерле икәнен аңлыйсың. Аңлыйсың да онытасың. Чөнки ул күп. Чөнки ул бушлай. Бушлай диярлек...

Суның иң кирәкле нәрсә икәнен аңлау өчен, шәһәрдәге фатирыңның «стояк» дип аталган торбасын алыштыру кирәк. Безнең йортта ул хан заманыннан калган торба инде. «Быел алыштырырга тиешләр икән», – дип сөйли башлауларына гына да ун ел чамасы. Хөкүмәтнең быел дигәнен ун ел көтәргә кирәк. Көтәсең инде... Син барып, аның газын өзә алмыйсың, электрын аера алмыйсың, штраф сала алмыйсың, судка бирә алмыйсың... Син берни дә эшли алмыйсың. Көтә генә аласың.

Быел без көтеп алдык. Башладылар. Көтеп алган нәрсә көтмәгәндә килеп керде һәм көтелмәгәнчәрәк булып чыкты. Ишек тукылдаттылар да:

– Сез өйдәме? – дип сорадылар. «Без өйдә юк», – дип әйтсәк, борылып чыгып китәрләр иде микән, тик без алдашмадык, өйдә, дидек. Шуннан болар:

– План буенча торбаларны алыштырырга кирәк. Рөхсәт итәсезме? – диделәр.

– Әлбәттә!!!

Рөхсәт итми диме соң! Фатир эчендәге бөтен торбаны алыштырасы бар. Тик монысын яңартмый торып, аларны булаштыруның файдасы юк. Торбаларны чыгарганда ваннаңны да, туалетыңны да беркадәр җимереп китәчәкләр. Шуңа күрә... Кыскасы, без ризалаштык. Шатланып. Болар, кереп, торбаны кисеп алдылар, аны чыгарганда берничә кафельне чәрдәкләделәр, ишек яңагын имгәттеләр, идән дә үз төсен җуйды. Бөтен дөнья тузанга батты. Без аны себереп алдык инде, тик юып булмады. Су юк.

Хәзер яңа торба куярга тиешләр. Бүген кичкә яки иртәгә булыр инде... Әһә менә! Булды, ди!

Яңаны кую өчен, бөтен подъездның торбаларын алып чыгарга кирәк икән. Бернинди дә белдерү булмагач, аларны колач җәеп көтеп торучы юк. Кеше бит ишек ачарга да куркып яши хәзер. Башта коронавирус керер дип курыктылар, хәзер участковый яки военкомат вәкиленнән шүрлиләр. Бернидән шүрләмәгән кешеләр дә өйдә ята алмый, һәркемнең ипотекасы яки кредиты бар, аны түләргә кирәк. Ә акча ул повестка түгел, аны тик торганнан өеңә китереп бирмиләр. Шуңа күрә халык эшләргә, бер урыннан икенчесенә чабарга мәҗбүр.

Вәт менә шул. Күршеләрне өйләрендә очрата алмый интегәләр. Алынган торба урыны серәеп тора, фатирда су юк. Әллә ничә көн инде. Ә фатирда иң кирәкле нәрсә су икән. Чәй эчәргә кирәк, аш пешерергә кирәк, савыт-саба юарга кирәк, өстәлне чистартырга кирәк, идәнне юарга кирәк, кер уарга кирәк... Нәрсәгә генә тотынам дисәң дә, су кирәк икән. Хәтта хаҗәтханәңнән үлгән ризык исләре чыгып, бөтен дөньяны тутырмасын өчен дә су кирәк. Без аны элек белмәгәнбез генә икән. Сулар һава шикеллерәк дип уйлаганбыз. Күп, арзан, шулай булырга тиешле.

Алай түгел икән. Дөньяда иң кирәкле нәрсә – су, ә иң кадерле җан ияләре торба алыштыручылар икән. Чөнки аларның икесе дә дефицит. Ярый инде, без, аяк-куллары хәрәкәттә кешеләр, бераз җаен табарга тырышабыз. Кибеттән су сатып алып, өйдәге зур савытларны тутырып куябыз, бетсә, тагын чыгып алабыз. Күрше йортта яшәгән танышларның хәлен белешергә кергән булып, туалетларында «кулларны чайкап» чыгабыз. Кер җыелып китсә, прачечныйга илтәбез. Карын ачса, берәр хакимият йортындагы ашханәгә барып, арзанга ашап чыгабыз. Сау-сәламәт кеше ничек тә җаен таба инде. Тик менә өске катларның берсендә бик өлкән яшьтәге кешеләр яшәгән булган икән. Күршеләре: «Мәет исе килә бугай», – дип, бик зарлангач, полиция килеп, ишекләрен ватып ачкан. Мәет булмаган, хаҗәтханә исе булган. Карт белән карчык икесе дә өлкән яшьтә булганлыктан, урамга суга чыгарлык хәлләре юк икән. Суга сусап сасыганнар, кыскасы. Элек икесе дә атеист иде. Хәзер дин юлына басканнар.

Юк, зарланып язмыйм мин боларны. Киресенчә. Чиксез горурлык һәм әйтеп бетергесез патриотизм хисләре белән илһамланып язам. Бары тик бездә генә кешеләрне рухи яктан үстерү, аларның акылын үткенрәк, хисләрен тирәнрәк итү өчен котылгысыз шартлар тудырылган. Югыйсә без суның мөһимлеген дә тиешенчә аңлый алмый торган денсезләр булып гомер уздырыр идек. Ә болай... Рәхмәт сезгә! Һәрбер эшне җиренә җиткереп уйлап, алдан корган планнардан чүт кенә дә тайпылмыйча эшли торган акыл ияләренә, кеше өчен өзелеп торучы фидакарь хезмәтчәннәргә, һәммәгезгә дә рәхмәт. Үз яхшылыгыгыз үзегезгә кайтсын. Бише белән!

Марат КӘБИРОВ

Ватан хакына

«Аларны ташлап китә алмыйм»

ЗӘЙ ЕГЕТЕНЕҢ БАТЫРЛЫК КЫЙССАСЫ

Зәй

Моннан җиде ай элек – 19 апрельдә Украинада махсус хәрби операция барышында якташыбыз, Поручик авылыннан 22 яшьлек Дмитрий Милочкин һәлак булды. Без Милочкиннар гаиләсендә булып, егетнең әти-әнисе, якыннары белән сөйләштек.

Йортта һәр бүлмәдә Диманың фотосурәтләре тора. Әниләре алардан күзен дә алмый. Милочкиннар гаиләсендә 5 малай үсә. Дима – икенче бала. Тырыш, җаваплы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, тәртипле – якыннары, классташлары, дуслары, укытучылары аның әнә шул сыйфатларын искә ала.

– Дуслары һәрвакыт күп булды. Урамда үзеннән кечкенәләр дә аңа ияреп йөрде. Көчле, максатына омтылучан, мәрхәмәтле, гел елмаеп кына тора, бик аралашучан иде. Ул минем уң кулым булды. Бик сагынам улымны, ул җитми миңа, – ди әнисе Людмила Михайловна.

Егет Поручикта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Чаллы төзелеш көллиятенә укырга керә. Биредә абыйсы Вадим да белем ала. Көллияттә дә ул үзенә дуслар таба, футбол белән ныклап шөгыльләнә башлый. Укуын тәмамлаганнан соң егет 2019 елда язгы чакырылышта Ватан алдында хәрби бурычын үтәргә китә. «Мин хәрби хезмәткә барачакмын, дип, кечкенәдән үз сүзен катгый итеп әйтеп килде», – дип искә ала әнисе.

Егет армия хезмәтен Хабаровскида уза, аннан соң контракт төзи. «Бу хакта безгә килешү төзегәннән соң гына әйтте. Бу – аның үз теләге буенча сайлаган һөнәре, мин ирләрчә аны хупладым гына», – дип сөйли әтисе Федор Анатольевич.

Быел март ахырында Диманы махсус хәрби операциягә җибәрәләр. «Улымның Украинага барырга җыенуы турында белгәч, бу хакта уйлый да күрмә, дип, аны бу уеннан кире кайтырга күндерә башладым. Анда безнең егетләр, мин аларны ташлап китә алмыйм. Үзеңне минем урынга куеп кара, диде», – дип сөйли әнисе.

Дима Украинадан якыннары белән нибары өч мәртәбә элемтәгә чыга. Соңгы сөйләшү 18 апрельдә була. Шуннан соң аннан хәбәрләр булмый. 4 майда егетнең Сахалиндагы иптәшләреннән, аларның хатыннарыннан куркыныч хәбәрләр килә. Ана күңеле ышанырга теләми. «Мин улымның исән булуын теләп Ходайга ялвардым. Ахырга кадәр аның белән барысы да яхшы булуына ышандым...» – ди Людмила Михайловна, яшьле күзләрен сөртеп. Өметне өзгән документта Дмитрий Милочкинның 19 апрельдә Луганск Халык Республикасы территориясендә барган хәрби операциядә батырларча һәлак булуы турында әйтелә.

Хәрби часть командиры урынбасары, капитан Даниил Малов түбәндәгеләрне сөйли:

– Һөҗүм вакытында Дмитрий хезмәт иткән подразделение нацистларга каршы көрәш алып бара. Оборона сызыгында Дмитрийның танк экипажы засадага эләгә. Ул дошманга алга барырга мөмкинлек бирмичә, иптәшләрен уттан каплап, коткарып калды. Дмитрий хәрби бурычын чын геройларча үтәде. Аның батырлыгы – Россия Кораллы Көчләрендә хезмәт итүче барлык кеше өчен көчле рух, профессионализм үрнәге.

Дмитрий үзенең көндәлегендә һәр көнне нәрсә эшләгәнен, кайда булуын язып барган. Командиры аның шәхси әйберләрен гаиләсенә алып кайтып тапшырган. Бу әйберләр арасында көндәлек тә бар. Хәзер ул – Милочкиннар гаиләсе өчен кадерле ядкарь. Икетуган сеңлесе Ангелина көндәлектән Диманың бер истәлеген укый. Егет 14 апрельдә подвалга төшүе һәм анда ике кечкенә бозауның чыга алмыйча азаплануын күрүе, аларга ярдәм итәргә тырышуы, ләкин шул вакытта аларны атакага чакырып алулары турында язган.

Күптән түгел Людмила ханым улын төшендә күргән. «Ул миңа карап елмая, әмма дәшми», – ди газиз улын югалткан әни. Дмитрий Милочкин, үлгәннән соң, Батырлык ордены белән бүләкләнде, тиздән аны батырның әти-әнисенә тапшырачаклар.

Клара ЕРМОЛАЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы хезмәткәрләре: чаралар оештыру бүлеге җитәкчесе **Аделшин** Адил Азат улына, проректор – академик сәясәт һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы **Бобров** Евгений Сергеевичка, проект һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге идарәсе башлыгы урынбасары **Данилов** Евгений Вадимовичка, аналитика бүлеге финанс директоры **Зотов** Павел Михайловичка, белем бирүнең сыйфаты буенча проректор **Ходырева** Елена Анатольевнага, профессор-укытучылар составын җәлеп итү һәм аларга булышлык күрсәтү бүлеге җитәкчесе **Циунчук** Тимур Рөстәм улына, **«Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы коллективына Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Уяу булыйк!

aleksejevsk.ru

Утның теле аяусыз

Татарстанда янгыннар саны да, шулар аркасында зыян күрүчеләр дә, үлүчеләр дә кими. 22 ноябрьгә булган мәгълүматларга карасак, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, янгыннар саны 1204 очракка кимегән. Үлүчеләр – 51, янгын аркасында зыян күрүчеләр саны 17 кешегә кимрәк.

Ут белән гел сак булырга кирәк. Көз-кыш айларында, һава температурасы түбән чорда бигрәк тә. Димәк, уаулыкны икеләтә арттыру зарур. Татарстанда 4256 янгын очрагы теркәлгән. Белгечләр мондый вазгыятьне канәгатьләндерерлек дип бәяли.

Гомуми саннарның кимүенә ирешсәләр дә, кайбер районнарда зыян күрүчеләрнең дә, үлүчеләрнең дә артуын күзәтәләр. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе башлыгы урынбасары Максим Трущин бу елның утлы вазгыятенә бәя бирде һәм ул-бу булмасын өчен нишләргә кирәк икәнен искә төшерде.

Яз-җәен ут теле күпчелек очракта табигый мохитне камап ала. Максим Трущин искәрткәнчә, һава температурасы түбәнәйгән чорда янгыннар ешрак сарай, мунча, шәхси һәм күпфатирлы йортларда чыга.

– Узган елның көз-кыш айларында 2985 янгын чыкты. Шуларда 83 кеше үлде, 89ы төрле җәрәхәтләр алды, – диган мәгълүмат китерде идарә вәкиле. – Торак секторына янгыннарның иң күп өлеше туры килә. Узган ел 1103 очрак шунда чыкты. 79 кешенең гомере өзелде.

Моннан тыш 935 очрак мунча-сарайларның януына туры килә икән. Ут-ялкыннан 485 күпфатирлы һәм 460 шәхси йортка зыян килгән. Монда үлүчеләр саны да күбрәк (гомуми күрсәткечнең 52 проценты).

Битарафлыкмы, җавапсызлыкмы, очраклы хәлме? Максим Трущин янгыннарның сәбәпләрен дә санап узды.

– Гомуми статистика шуны күрсәтә: янгыннарның күп өлеше яткан җирдә тәмәке тартудан килеп чыга. Кеше кулына тәмәке тоткан килеш йоклап китә. Бу янгынга бер сәбәпче була да инде. Ул әллә ни зур мәйданны колачламаса да, аяныч фаҗигага китерергә бик җиткән, – диде ул. – Ут белән сак булмау, электр җиһазлары һәм мичләреннән дөрес файдаланмау да янгынга китерә.

Фаҗигале очракларның күпчелеге кешеләрнең хәмер кулланган һәм йоклаган чакларына да туры килә. Үлүчеләрнең 39 проценты пенсия яшендәгеләр булса, 25 проценты – эшсезләр.

Максим Трущин әйтүенчә, янгыннан саклану өчен иң гади кагыйдәләрне истән чыгармаска кирәк. Җиһазлар белән эш иткәндә бигрәк тә. Аларның тезкеләгенә игътибар итәргә һәм инструкциядәге таләпләргә дә битараф калмаска. – Җылыткыч җиһазлар челтәр, пәрдәгә якын тормасын. Җиһазлар өстендә кием-салым киптерү дә хәерле түгел, – диде Максим Трущин. Җылы бирә торган пичләр турында гына түгел сүз. Электр чәйнеге, үтүкләр дә шуңа керә. Газ белән эшли торган җиһазлар да – шул исемлектә.

Электр чыбыкларының тезкелегенә дә битараф калырга ярамый. Очкынлап тора икән, алмаштырыр вакыт җиткән диган сүз. Бу эшне озакка сузып йөрү кирәкми. «Тиксеру, алмаштыру өчен махсус белгеч чакыртырга кирәк итәбез», – дип өстәде Максим Трущин.

Белгеч аерым игътибарны балаларга бирергә куша. Ут белән сак булырга да өйрәтәсе, сабыйларны үзләрен генә ул-бу булырдай урыннарда калдырмыйсы. «Янгын балаларны да аямый. Кызганыч, былтыр янгыннарда 6 баланың гомере өзелде. Быел өч бала үлде. Тагын бер кат ата-аналарга мөрәҗәгать итәсе килә: балалар күзәтүсез калмасын иде. Өлкәннәргә генә дә ышанып калдырырга кирәкми. Балаларга, янгын була калса, нишләргә икәнен өйрәтергә, аңлатырга кирәк», – диде идарә белгече.

Максим Трущин өйләргә янгын турында кисәтүче махсус җиһаз урнаштырырга киңәш итте. «Без бу эшне үзебез дә башкарабыз. Ялгыз яшәүчеләргә, күпбалалы гаиләләргә, пенсионерларга, сугыш ветераннарына, авыр хәлдәге гаиләләргә бюджет хисабыннан 300 меңнән артык җиһаз урнаштырдык. Быел 48 мең җиһаз урнаштырылды. Әлеге җайланманың нәтиҗәсен күрдек инде: быел 26 кешенең гомерен коткарып кала алдык», – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

ГӨЛШАТ ИМАМИЕВА:

«АРТИСТ ТОРМЫШЫ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ»

Гаиләдә икең дә иҗат кешесе булгач, тормышны алып бару җиңелрәкме? Җырчы да, әни дә, яхшы хуҗабикә дә була алуның сере нәрсәдә? Бүгенге заманда җырның тәрбия көче калдымы? Татарстанның атказанган артисты, Казан шәһәре филармониясе солисткасы Гөлшат ИМАМИЕВА белән әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Гөлшат ханым, сезнең дөньяга аваз салуыгыз үзе бер вакыйга икән. Тормышыгызга йогынты ясамый калмагандыр ул?

– Әнием мине «Энергоинститут» тукталышындагы ипи кибете бусагасында тапкан. Транспорт юк чак бит инде, әти белән икесе хастаханәгә җәяү киткән булганнар – өлгермәгәннәр. Әни җаным, шуны искә алганда, үзем оялдым, нишләргә белмәдем, ди торган иде. Узып баручылар да аптыраган инде, туктап: «А вы что там делаете?» – дип сораганнар. Минем кендек әбием ролен башкарган әти шулары: «Не видите что ли, рожаем!» – дигән. Анекдоттагы кебек булган инде *(көлә)*. Тугач та, әтинең яңа костюмына төреп, «ашыгыч ярдәм» килгәнен көткәннәр. Еламагач, әни кайгырган инде. «И, кыз бала икән… Улмәсә генә ярар иде», – дип, теләкләр теләгән. Минем бит абыем да 2 яшеннән бирле авырган. Курыккан инде җаным.

Бу хәлнең тормышыма шулкадәр зур йогынтысы булды дип әйтә алмыйм. Ләкин үлемнән калган тагын бер очрак булды. Безнең фатир янында сазлык бар иде. Анда батып үлүчеләр дә булды. Мин дә өч яшьлек чагымда чыгып китеп югалганмын. Ул чакта апаларым карап торырга тиеш булган. Бар җирне әйләнеп тә таба алмагач, батып үлгән инде бу, диешкәннәр. Берзаман әллә кайдан бала тавышы ишетелгән. Барып карасалар, бер ирле-хатынлы гаилә табып, мине кулларына алганнар. Ә мин үкереп елыйм икән. «Әнисе кайда соң моның?» – дип сүгәргә тотынуга, әни килеп чыккан. Эштән кайткан вакыты булган инде аның. Нигә сүккәннәрен аңламаган җанкаем. Менә ул чакта да Аллаһы Тәгалә саклаган инде мине.

:: Сез кечкенәдән җырчы булам дип үскән баламы?

– Балалар бакчасында ук музыкаль мәктәпкә бирергә кушканнар мине. Күрәсең, әти белән әнинең мөмкинлекләре дә, вакытлары да булмаган. Ләкин аңа карап җырлаудан туктамадым. Ә беренче тапкыр олы сәхнәгә чыгуым әниемнең эшенә бәйле. Ул үзе дә һәвәскәрләр ансамблендә җырлап йөри иде. Шунда мине җитәкләп алып барганы хәтердә. Аннан әле, «эшкә урнаштырып», Түбән Новгородка конкурска да җибәргәннәр иде.

:: Җыр-моңга мәхәббәт – әниегездән, димәк?

– Әни дә, аның апасы белән сеңлесе дә җырлый иде. Шундый моңлы гаиләдә үскәч, миңа башка чара калмагандыр инде. Ә дәү әни: «Кирәкми, артист булма, кызым», – диган иде. Аның бу сүзләре чемодан-сумкаларымны тутырып, юлга чыккан саен искә төшә.

:: Җыр – нәрсә ул сезнең өчен?

– Тормыш.

:: Нишләп бу юлны сайладым икән, дип үкенгән чакларыгыз буламы?

– Булгандыр инде. Ни генә дисәләр дә, артист тормышы җиңел түгел. Ирем белән икебез дә иҗат дөньясында (аның тормыш иптәше Дамир Имамиев – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты. – **Авт.**) кайнагач, ничектер барган инде тормыш.

:: Нинди җырлар якынрак сезгә?

– Тирән мәгънәле. Күңелгә тия торган булсын.

:: Бүген халыкның андый җырларны азрак тыңлавы күңелегезгә тиямә?

– Нәрсә тәкъдим итәсең, шуны тыңлый инде кеше. Радиодан ротациягә кем нинди җыр бирә ала, шуны куялар бит. Акчага килеп терәләгч, шулай инде. Тәрбия турында әйтеп тә тормыйм, аны без 30 еллап элек югалттык. Яшьләр хәзер нәрсә белә? Әүвәлге җырчыларыбызны, күренекле автор һәм композиторларыбызны беләме алар? Юк. Әйтерсең, безнең җыр сәнгатендә опера һәм симфонияләр бөтенләй булмаган. Беркаян да ишетелмәгәч, менә шундый хис кала инде.

:: Соңгы арада шәһәр филармониясе яңа форматларга еш мөрәҗәгать итә. Аларны кабул итү авыр булмадымы?

– Бу бит инде – замана таләбе. Дөресен генә әйткәндә, пандемия чорында өйдә утырганда ук, тик тора алмаганлыктан, сценарийлар яза башладым. «Сабантуйга – Австралиягә» тамашасының сценарие шул чакта язылды. Аннан Ләйсән Мәхмүтова, Алсу Сөнгатуллина һәм мин язган сценарий буенча «Көтегез, без килабез» фильмын төшердек. Шөкер, ниятебезне чынга ашырырга мөмкинлек табылды. Башта фикерләр, идеялар күп әле ул – рәхәтләнеп эшләргә була. Ләкин бөтен нәрсә акчага килеп төртелә шул…

Яңа форматлар белән эшләү – артист өчен яхшы тәҗрибә дә ул. Мин – җырчы, дип утырмыйсың, актер да буласың, биисең дә. Менә безнең артистлар да бөтенләй башка яктан ачылды, миңа калса. Аннан соң, язып артистларың булмаса, яңалык кертү кыен булыр иде. Шөкер, бер урында таптанмыйбыз, замана белән бергә атлый алабыз.

:: Сәхнә гаилә тормышын алып барырга комачауламыймы?

– Төрле чаклар булды инде. Мин кайтып кереп, ирем чыгып киткән, йә икаулашеп өйдә булмаган вакытлар да булгалады. Балаларыбызның олысы – әби-бабай янында, кечкенәсе апалар белән авылда үсте. Хатын-кыз булгач, аларны калдырып чыгып китү икеләтә авыр иде инде.

:: Улыгыз белән кызыгызның үпкә белдергән чаклары булмадымы?

– Беренче сыйныфка барып, укытучылары: «Әниең дә – артист, әтиең дә – артист, синнән дә артист ясыйбыз, җырлатабыз», – дигәч, улымның: «Булмыйм мин артист. Кирәкми миңа андый эт тормышы», – дигәне исемдә. Ләкин геннар үзенекен итте: вокалга да йөрде, гитарада да уйнарга өйрәнде. Хәзер башка юлны сайлады.

:: Кызыгыз да иҗатка якынмы?

– Кызыбыз рәсем сәнгате белән кызыксына. Бөтенләй икенче төрле инде ул. Шулкадәр нечкә күңелле, беребезгә дә охшамаган.

:: Гөлшат ханым, иҗатта кайнаган кешеләр, гадәттә, хыялый, хисле була. Сезнең гаиләдә хыяллардан җиргә төшерүче ролен кем башкара?

– Ничек кенә булса да, ир кеше – ир кеше инде ул. Ул булганга мин тыныч. Аның кебек терәгем, таянычым булмаса, болай иркенләп йөри алмаган да булыр идем.

:: Сезне, бик уңган хуҗабикә, диләр. Әни дә, җырчы да булып, өйдәге мохитне дә көйләргә җай табу җиңелләрдән түгелдер…

– Татар хатын-кызының канына сеңгәндер инде ул. Безне кечкенәдән, гаилә беренче урында булырга тиеш, дип тәрбияләделәр. Ничек кенә булса да, сабыр итәргә өйрәттеләр. Өйдә һәрвакыт тәртип, табында һәрвакыт ризык булуны тиеш әйбер итеп кабул итәбез. Тәрбиядәндер дим мин аны.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Гөлшат ханымның бик тәмле итеп бәлеш пешерүен белгәч, рецептын сорадык. Сезгә дә тәкъдим итәбез. Тәмле булсын!
Камыр өчен 1 стакан сөт, 1 стакан сыек май, ярты аш кашыгыннан азрак тоз, 2–3 аш кашыгы шикәр комы, 9 гр камыр көпшәкләндергеч һәм он кирәк.
Эчлек өчен үзегез яраткан ит (үрдәк, каз, сыер итеме – мөһим түгел), 3 баш суган, итенә карап бәрәңге һәм тәменчә тоз белән борыч кирәк.

ТУЛАЙ ТОРАК БӘХЕТКӘ КҮЛӘГӘ ТӨШЕРМИ

ИЛЬЯСОВЛАР БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘ СЕРЕН АЧТЫ

Дөньяда меңләгән затлар арасыннан үз кешеңне табу – иң зур бәхеттер инде ул. Ятратканың белән бар мизгелләрне бергә үткәрүдән, кайгы, шатлык белән уртаклашудан кала тагын ни кирәк… Тик гомер буена шушы мәхәббәтне саклап буламы соң? Була икән. Моңа дәлил – 44 ел бергә гомер иткән Ильясовлар гаиләсе.

Хисле яшь чаклар

Сөю хисләре әчтә күбәләкләр уята, диләр. Спас районының Көек авылында туган Рәхилә һәм Йосыф Ильясовлар мәктәп елларында ук бер-берсенә гашыйк булалар.

– Бергә кулга-кул тотынышып авыл урамнары буйлап йөри идек, – дип искә төшерә Рәхилә апа. – Аннан Казанда язылышып, авылга кайтыйбыз… Ул вакытта паромда йөри идек әле. Паромда биеп, җырлап, ярның теге ягына чыгып җиткәнебезне сизми калдык. Кайтуга, авылда гөрләтеп туй уздырдык. Әле һаман да безгә: «Шундый күңелле туйда булганыбыз юк», – диләр.

Тормышның һәр мизгеле – кеше өчен кадерле байлык ул. Йосыф абый да: «44 ел бергә тормыш иткән вакыт эченә сыйган мизгелләрне санап китсәң, саннар җитмәс кебек», – ди.

Үткәннәрне искә төшерү Рәхилә ханым йөзенә елмаю өстәде.

– Иптәшем миңа бер вакытта да каршы килмәде. Кияге килгән киемнәрне дә, ал, дип кенә тора иде. Кая барырга теләдем – диңгезгәме, театр, концертками, гел бергә йөрдек, – ди ул.

– Өйләнешкәч, бер бүлмәле тулай торакка күчтек. Әллә ни зур булмаган бер бүлмәдә 22 ел яшәсәк тә, үзебезне бәхетле хис иттек, – дип сүзгә кушыла Йосыф абый да. – Өебез тулы кунак, өстәлебез тулы ризык, аяк арасында балалар йөгереп йөри. Шушы вакытлар яшь чакның иң кызык мизгелләре булгандыр да инде. Хәзер фатир алганыбызга да 22 ел үтеп китте. Монда икенче төрле тормыш башланды. Балалар менә дигән булып үстеләр, кияүгә чыгып, безгә оныклар бүләк иттеләр. Хәзер инде алар – безнең өчен иң зур сөенеч.

Рәхилә белән Йосыф Ильясовлар арасындагы мәхәббәт җылы сүзләреннән генә түгел, карашларыннан ук сизелә. Йосыф абыйның: «Үзем сөйләп тормыйм, карчык белән генә килешәм», – дип әйтүе, ә Рәхилә апаның: «Үзен һади Такташ шигырендәге Мокамайга охшатып куям. Кара чәчле, коңгырт кара күзле, кәкре аяклы тормыш иптәшем шундый бит минем!» – дип көлеп шаяртуы да бәхетле гаиләдәге җылы мөнәсәбәтләрне расләй.

– Җитдирәк әйткәндә, тормыш иптәшем – кешелекле, ярдәмчел, ирләргә хас булган сөйкемле зат, – дип өстәп куярга да онытмый Рәхилә апа.

Гомерлек мәхәббәт сере

– Гомер буена мәхәббәтне саклау сере – бер-берене яратып, хөрмәт итеп, мәхәббәттән туган балаларны бергә яратып үстерүдә, – ди Рәхилә Ильясова. – Тормышта төрле хәлләр булды инде. Кайчысы да, шатлыгы да. Бәтенесен дә бергә кичердек. Авыр чакларда бер-беребезгә терәк булдык. Мин еласам, минем белән бергә Йосыф та елый иде. Гомерлек мәхәббәтнең сере шул: бер-береңне аңлап яшәргә кирәк. Дөрес, тормышта төрле чак була. «Без бер дә ызгышмадык», – дип сөйләүчеләргә мин ышанмыйм. Әйткәләшеп киткән чакларыбыз бик тиз генә уза иде. Ике-өч көн сөйләшмичә йөргән чагыбызны хәтерләмим дә. Еллар узган саен кешегә якынрак буласың бит инде. 44 ел – аз гомер түгел…

…һәр парның үз мәхәббәт сере була торгандыр. Ильясовлар гаиләсендә ул аңлашуга, ярату нигезләнгән. Рәхилә апа белән Йосыф абый бергә үткәргән һәр мизгелнең тәмен белеп яши. Яшь чактагы сөюне әле дә саклап, бергә гомер итү – зур бәхет инде ул.

Ильясовларның шәхси архивыннан

Эльвина ПОЛЯКОВА,
КФУның 1 курс студенты

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 377

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+